ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«_8_» _февраль_ 2019 ел** **№ _57_**

**«ТР Арча муниципаль районының Урта Бирәзә авылында Һ. Такташ урамында газүткәргеч тармагы» Газпром трансгаз Казан «ҖЧҖ нең линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45,46 статьялары, Татинвестгражданпроект ДУП тарафыннан Газпром трансгаз Казан ҖЧҖ заказы буенча, Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары нигезендә, объектның территорияләрен планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләү буенча эшләр комплексы, Арча муниципаль районының Иске Айван» программасы буенча Арча муниципаль районы территориясен тотрыклы үстерү, планлаштыру структурасы элементларын билгеләү, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатыннан, Арча районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Газпром трансгаз Казан ҖЧҖнең «ТР Арча муниципаль районының Урта Бирәзә авылында Һ. Такташ урамында газүткәргеч тармагы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерли башларга.

2. «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖне территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләүгә заказчы итеп билгеләргә.

3. Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә объектны планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләүне мәгълүмат белән тәэмин итәргә.

4. Кушымта нигезендә территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләүгә техник биремне расларга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ttp:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И. Ә. Галимуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516